**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КОМСОМОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«27» марта 2026 ел № 9/1

**Җир салымы турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 31 бүлеге, 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Комсомол авыл җирлеге территориясендә әлеге территориядә түләнергә тиешле җир салымын билгеләргә.

2. Җирнең кадастр бәясеннән җир салымының салым ставкаларын түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

- 0,3 % түбәндәге җир кишәрлекләренә карата:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки торак пунктларда авыл хуҗалыгыннан файдалану зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә кертелгән;

2) торак фонды һәм (яки) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләреннән тыш);

3) мәгариф, фән, сәламәтлек саклау, мәдәният һәм спортның административ һәм офис объектларын урнаштыру өчен җирләргә кертелгән;

4) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән), шулай ук «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре, 2018 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла;

5) РФ законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборонаны, куркынычсызлыкны һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән;

6) торак фонды биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм (яки) торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш);

- 0,05% 1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юллары төзү һәм алардан файдалану өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата;

- 1,4% авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки торак пунктларда авыл хуҗалыгыннан файдалану зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә карата;

- 1,5% башка җир кишәрлекләренә карата;

- 1,03% сәнәгать, коммуналь хуҗалык, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сату һәм әзерләү җитештерү һәм административ биналарын, корылмаларын урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата;

- 0,001%Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан вәкаләт бирелгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге №69-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатында.

3. Җир салымы буенча салымнан тулысынча азат итү өлешендә түбәндәгеләргә ташлама билгеләргә:

1) Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары;

2) инвалидлыкның I һәм II төркемнәре булган инвалидлар;

3) балачактан инвалидлар;

4) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, шулай ук сугышчан хәрәкәтләр ветераннары һәм инвалидлары;

5) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә, 1998 елның 26 ноябрендәге 175-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә булган авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» һәм «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм алу хокукына ия физик затлар;

6) махсус хәвеф-хәтәр подразделениеләре составында атом-төш һәм термоатом-төш коралын сынауларда, кораллану чараларында һәм хәрби объектларда атом-төш җайланмалары һәлакәтләрен бетерүдә турыдан-туры катнашкан физик затлар;

7) атом-төш коралын һәм космик техниканы да кертеп, теләсә нинди атом-төш җайланмалары белән бәйле сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы алган яки кичергән яки инвалидка әйләнгән физик затлар;

8) авыл җирендә яшәүче һәм пенсиягә чыккан ялгыз пенсионерларга;

9) оешмаларга - гражданнар каберлекләре булган җир кишәрлекләре;

10) җир кишәрлекләрендә җирле бюджеттан финанслана торган казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр урнашкан оешмаларга;

11) җирле үзидарә органнарына – милек хокукында һәм даими вакыты чикләнмәгән файдаланудагы үзләренең җир кишәрлекләренә.

12) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, РФ Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел №647 Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары. Салым ташламасы салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

4. Салым түләүчеләр – оешмалар өчен календарь елның беренче, икенче һәм өченче кварталлары хисап чоры дип таныла дип билгеләргә.

Салым түләүчеләр – оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясе процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 өлеше күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

5. Әлеге карар белән билгеләнгән салым ташламалары арендага (файдалануга) тапшырыла торган җир кишәрлекләренә (кисәкләренә, өлешләренә) кагылмый дип билгеләргә.

6. Салым ташламаларына, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турында законнарда билгеләнгән салымны кире кайтару рәвешендә, хокуклы салым түләүчеләр салым органына үз теләкләре буенча салым ташламасы бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар тапшырырга хокуклы.

7. Әлеге карар мәгълүмат стендларында һәм районның рәсми сайтында рәсми игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

8. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы « Комсомол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2017 елның 26 сентяберендагы №7/2 номерлы карарының (26.12.2017 ел № 11/2; 24.09.2018 ел № 7/5; 25.10.2018 ел № 8/3; 08.11.2019 ел № 10/1; 28.02.2020 ел № 1/6; 07.06.2021 ел № 9/1; 02.07.2021 ел № 11/1; 14.11.2023 ел № 35/1 карарлар үзгәрешләре белән) гамәлдә булуы үз көчен югалткан дип танырга.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе — О.В. Сурова